ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19,с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район 422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Г.Тукай урамы, 19 йорт,
Ашытбаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**Ташкичү авыл җирлеге Советы карары**

**03 октябрь 2022 ел** **№ 22**

**Аерым норматив-хокукый актларның үз көчләрен югалтуын тану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясындагы 1 өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының «Арча муниципаль районы Иске Ашыт авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеген туктату турында» 2011 елның 6 декабрендәге 1.7 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Ашыт авыл җирлеге башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Ашыт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексын раслау турында» 24.02.2011 №1;
- «Иске Ашыт авыл җирлегенең Иске Ашыт торак пунктлары чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына юл сервисы объектларын кушу буенча хезмәт күрсәтүләрнең бәясен һәм исемлеген раслау турында» 07.08.2010 № 59.2.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http:arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Хабибуллин